**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 151** **27.12.2024 г**

**Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 161 номерлы «Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы «Дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законга, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы законнарына,2023 елның 9 мартындагы 16-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм “Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында”гы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына, Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы

карар итте:

1.Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 161 нче номерлы карары (17.04.2015 №241а, 29.05.2018 №141, 05.11.2019 № 214, 15.07.2021 № 37, 29.06.2022 № 67, 17.11.2023 № 106 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә расланган Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегендә бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 8 нче пунктында

а) 26 нчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән «Электрон бюджет» мәгълүмат системасында федераль бюджет акчалары булган капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булган капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш);»;

б) егерме алтынчы - илле икенче абзацларны тиешенчә егерме җиденче-илле өченче абзацлар дип санарга

1.2. Өченче абзацның 35 нче пунктындагы «беренче биш эш көнендә» сүзләрен «бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча»сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны “Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында” бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), торак пунктлар территориясендә махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **С.К. Маклаков**